**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 октябрендәге 4377 номерлы карары**

**Казан шәһәре территориясендә**
**янгынга каршы махсус режим билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының, Татарстан Республикасында террорга каршы комиссиянең, Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча координация киңәшмәсенең һәм Татарстан Республикасы оператив штабының 2024 елның 18 сентябрендәге уртак утырышы беркетмәсен үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре территориясендә 2024 елның 18 октябреннән 26 октябренә кадәрге чорда янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда түбәндәгеләрне тыярга:

- учак кабызу, каты көнкүреш калдыкларын, коры үләннәрне һәм чүп-чарны яндыру;

- урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы зур булган торак пунктларда, балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары территорияләрендә, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бара торган, урман янгыннары куркынычы янаган территорияләрдә, шулай ук урман массивлары белән чиктәш икътисад объектларында (җәмәгать туклануы объектлары (рестораннар, кафелар, барлар һәм башка объектлар) территорияләрендә кулланыла торган мангаллардан һәм башка җайланмалардан тыш) янмый торган махсус савытларда (мангаллар, тимер учаклар һәм башка савытларда) азык әзерләү өчен ачык уттан, ризыкны җылылык белән эшкәртә торган башка җайланмалардан файдалану;

- урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы зур булган торак пунктларда, балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары территорияләрендә, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бара торган, урман янгыннары куркынычы янаган территорияләрдә, сәламәтләндерү оешмаларында, шулай ук урман массивлары

белән чиктәш икътисад объектларында, урман-парк зоналарында, торфлы урыннарда һәм ачык территорияләрдә куркынычлылык буенча 1 - 3 класслы пиротехник эшләнмәләр куллану;

- югары күтәрелү принцибы конструкцияләр эчендә ачык ут ярдәмендә һава җылытуга нигезләнгән ягулык материалларыннан ясалган, идарә ителми торган эшләнмәләр эшләтеп җибәрү.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**